теләр. Моның белән бәйләнешле рәвештә Хәзрәти Гомәрнең хатирәсе аңлатыла. Хәлифә булган вакытта Хәзрәти Гомәр Дамаскка барырга чыга. Аны Дамаскта армия командирлары каршы ала һәм анда йогышлы ваба чиренең таралуын, халыкның күпчелегенең бу чир белән авыруын белдерәләр. Хәзрәти Гомәр йогышлы авыру таралган шәһәргә кермәскә карар бирә һәм үзе белән килгән кешеләргә кире китәчәкләрен җиткерә. Аның бу карарына җавап итеп командирларның берсе: *“Аллаһының тәкъдиреннән качабызмы? Әгәр Аллаһы бу авырудан үлүебезне язган булса, болай да үләрбез”,* – ди. Хәзрәти Гомәр дә: *“Әйе, Аллаһының тәкъдиреннән янә аның язмышына качабыз. Аллаһының безнең белән бәйле нинди планы булуын белмәгәнгә күрә, бары тик тиешле чараларны күрдем һәм йогышлы авыру таралган шәһәргә кермим»,* - дип җавап бирә.

Моннан шул аңлашыла: әйе, язмыштан качып котылып булмый, әмма язмышымда нәрсә язылган булса, мине килеп алсын дип көтеп утырырга ярамый. Авыру, чир тәкъдир түгел, чарасы күрелергә тиешле вәзгыять. Кеше акылын кулланып, яшәвен дәвам иттерү өчен кирәкле чараларны күрергә тиеш. Әлбәттә, үлем - тәкъдирдер һәм авырудан кеше үләргә мөмкин. Монда дөньяның яшәеше, хәрәкәт итүе белән бәйле мисал китерергә мөмкин: Аллаһы дөньяның эшчәнлеге белән бәйле кануннар яралткан. Кеше бу кануннарны өйрәнү, тану һәм боларга яраклы рәвештә яшәвен дәвам иттерергә тиеш. Югыйсә, тормышын куркыныч астына куячак афәтләр белән очрашырга мөмкин. Мәсәлән, бүгенге көндә җир йөзенең нинди структурага ия булуын ачыклаучы тикшеренүләр алып барыла һәм моңа карап җир тетрәүләрнең кайсы төбәкләрдә тагын да күбрәк була алуы галимнәр тарафыннан билгеләнә. Шуңа күрә торак пункт төзелешләрен планлаштырганда, мөмкин булганча, бу төбәкләрне күз уңында тоту яисә бу җирләрдә җир тетрәүгә чыдамлы йортлар төзү зарур. Бу чараларны күргәннән соң да, үлемең җир тетрәүдән булса, әлбәттә, бернәрсә дә эшләп булмый. Әмма кеше язмышка тәслим булу өчен түгел, язмышны, язылганны яшәү өчен яралтылган. Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: кеше үзгәртә алмаячак әйберләрне аңлап, үзгәртә алачак әйберләр өчен тырышып, көч сарыф итеп яшәргә тиеш.

**Рәмзия ӘГӘ язмасы.**
*(“Иман” газетасыннан)*

# Үлгәннәр рухына җиңеллек

Хәдисләрдән аңлашылганча, исәннәрнең дога һәм садакаларыннан үлгәннәргә файда тия. Әбү Хәнифә: *«Тән гыйбадәтләренең (ураза, намаз, Коръән уку кебек) савабы ирешә»,* – дигән. Соңгы елларда гарәп илләре руханилары тәэсирендә кайбер хәзрәтләр ни доганың, ни башканың савабы үлгәннәргә ирешми дигән фикер тараталар. Алар үзләренә «ән-Нәҗем» сүрәсендәге 39 нчы аятьне *(«Кешегә һичнәрсә юк, бары үзе кәсеп иткән нәрсәсе генә»)* дәлил итеп китерәләр.

Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам әйткән: *«Адәм баласы үлсә, бөтен эше туктатылыр, бары өчесе генә аңа бәйле калыр: дәвамлы садака яисә аның өчен дога кылучы динле изге бала, яисә үзеннән соң файда китерүче калдырган гыйлеме».*

Кеше үз тырышлыгы һәм яхшы мөгамәләсе аркасында дуслар таба, балалар тудыра, хатын-кызларга өйләнә, яхшылыклар эшли, башкаларга ошый, аны якын күргән булалар һәм аңа карата миһербанлык хисләре туа, аның өчен дога кылалар, бу – аның куйган тырышлыгының нәтиҗәсе. Ә бу кешенең ислам динендә булуы бер мөселманның эшләренең савабы икенче мөселманга исән чагында һәм үлгәннән соң да ирешүенә иң зур сәбәп булып тора.

Коръән бер кешенең икенче кеше эшләгәннән файда күрүен инкарь итми. Ә бер кешенең икенче берәү эшләгәнне үзенә алуын, ягъни эшләмәгәнне эшләдем дию хаксызлык була. Чөнки башканың тырышлыгы шул тырышучының мөлкәте, теләсә, ул аны башкага бирә, багышлый; теләсә, үзенә калдыра. Бу фикергә каршы чыгучыларның *«Сез кылган эшләрегез өчен генә җәза күрерсез»* («Йәсин» сүрәсе, 54 нче аять), *«Берәү Аллаһыга буйсынып, изге гамәл кылса, файдалы эшләр генә эшләсә, файдасы үзенә. Әгәр берәү Аллаһыга карышып гөнаһларны, явыз эшләрне кәсеп итсә, газабы үзенә»* («әл-Бәкара» сүрәсе, 286 нчы аять) дигән аятьләр белән үз карашларын ныгытулары дөрес түгел. Чөнки әлеге аятьләрнең мәгънәсе – бер кешегә тиешле җәзаны башкага бирмәү.

Югарыда искә алынган хәдистә Пәйгамбәр галәйһис-сәлам файда ирешүе туктый, димәгән, үлгән кешенең үз эше туктала, дигән, ә инде исән калганның үзе эшләгәнен, теләсә – үзенә калдыра, теләсә – башкага бирә, багышлый һәм шул эшне савабы багышланучыга ирешә. Бу үз малыңнан башка кешенең бурычын түләп, аның өстеннән төшерү сыман.

Әхмәт, Әбү Давыт һәм Тирмизи риваятьләрендә Пәйгамбәр галәйһис-сәлам Корбан гаетендә корбан чалганнан соң әйткән: *«Әй Аллаһым, бу миннән һәм өммәтемдә корбан чалмаганнардан».* Корбан чалу кан чыгару белән хасил була. Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам бу эшен башкаларга да багышлады. Бу үзең эшләп тапкан акчаны үз теләгең белән кешегә бирү кебек.

Үлгәннең исәннәр догасыннан файда күрүенә Изге Китаптан дәлил: *«Дәхи табыш маллары ул мөһаҗирләр һәм ансарлардан соң кыямәткә хәтле килә торган мөселманнарның мохтаҗларына, мөһаҗирләренә, ансарларына.*

*Алар әйтерләр: «Әй Раббыбыз, безне ярлыка һәм бездән әүвәл иман белән дөньядан үткән дин кардәшләребезне дә ярлыка, безнең күңелләребездә иман китергән кешеләргә ачу-хөсетне урнаштырма. Әй Раббыбыз, Син, әлбәттә, йомшак вә рәхимле!»*

Бөтен өммәтнең килешүе буенча, мәет өчен җеназада һәм аны җирләгәннән соң дога кылу турында берничә сүз. Пәйгамбәр галәйһис-сәлам әйткән: *«Дин кардәшләрегезнең*



*киемеңне яндырачак, яки син аннан үзеңә яман ис ияртеп чыгачаксың».*

Шуңа күрә тәкъва мөселман Аллаһы Тәгаләне искә төшерүче, йөрәкләрне йомшартучы һәм үзләренең үгет-нәсыйхәтләре белән күзләргә яшь китерүче яхшы кешеләр янына барырга тырыша.

*«Әгәр өч кеше бергә булсагыз, арадан икегез яшерен рәвештә сүз сөйләшмәсен. Әгәр күп булсагыз, ул вакытта икегезнең генә серләшүегездән зарар булмас».*

*«Әгәр сезнең берәрегез үзенең мөэмин кардәшен Аллаһы ризалыгы өчен сөяр булса, ул аны аңа белгертсен».*

Һәрбер мөэмин сезнең дин кардәшегез булса да, аларның араларында берничәсе аеруча якын була. Әгәр берәрсен үзегезгә якын итәсез икән, аңа белгертегез, ул да сезне якын итсен.

*«Кеше кемне сөйсә, шуның белән бергә булыр».*

Ягъни, әгәр берәүнең холык, табигатен беләсегез килсә, шул кешенең дустына карагыз, чөнки алар икесе дә бер холыкта булалар. Әгәр шулай булмаса, димәк, аларның дуслыклары чын түгел.

*«Бер-берегезне көнаралаш зиярат итегез, дуслыгыгыз артыр».*

Кардәшләрне еш зиярат итү арада мәхәббәтнең артуына сәбәп була. Әмма ярату һәм мәхәббәт юлында да тиешенчә эш итү кирәк. Дус булдык дип, дуслар берберсенә авыр йөк булмаска тиеш.

Яхшылар белән дус бул, яманнар белән яхшы мөгамәлә кыл.

Холыкның түбәнлеге чарасызлык халәтендә беленер; фетнә-сынауларда фикернең. тотрыклылыгы беленер; хөкемдә холыкның ясалмалыгы ачыкланыр; малда намуслылыкка булган дәгъваның хакыйкате ачылыр; югары, абруйлы мәртәбәләргә ирешкәч, нәсел-нәсәпнең һәм тәрбиянең нинди икәнлеге беленер; авырлык килгәндә дуслыкның ныклыгы беленер. Башкалар белән низаглашу, үпкәләшү юлларын түгел, бәлки, үзара дуслык һәм тынычлык булдыру юллары турында күбрәк уйлап, шуның чараларын күрергә кирәк.

*(“Татар дини календаре”ннан)*

# Үзеңә тиңне сайла!

Гаилә кору, кешелек яратылганнан бирле, һәртөрле җәмгыять әгъзаларының мөһим вә мактаулы эшләреннән саналган. Шуның өчен Аллаһы Тәгалә һәрбер пәйгамбәрне җибәргәндә, бу мәсьәләгә кагылышлы хөкемнәрне дә төшергән. Ниһаять, хак ислам динендә гаилә мәсьәләсендә зур игътибар бирелгән.

Коръән-Кәримдә һәм хәдисләрдә гаиләне ничек булдыру, кем баш булырга тиеш, әгъзаларының хак-хокуклары вә үзара килешмәгәнлекләрне хәл итү юллары, димәк, гаиләгә кагылышлы бөтен мәсьәләләргә тәфсилле җаваплар бирелгән. Коръән-Кәримдә әйтелгәнчә: *«Без һәрнәрсәне парлы итеп барлыкка китердек. Шаять, сез уйлап карарсыз»* («әз-Зәрийәт» сүрәсе, 49 нчы аять).

*«Аллаһы сезгә үзегездән хатыннар булдырды һәм хатыннарыгыздан балалар һәм оныклар бирде, һәм сезне яхшы нәрсәләр белән ризыклады»* («ән-Нәхел» сүрәсе, 72 нче аять).

*«Һәм Аның аятьләреннән: Ул үзегезгә бергә торыр өчен сезнең үзегездән хатыннар барлыкка китерде һәм арагызда мәхәббәт вә мәрхәмәтлек ясады. Хакыйкатьтә, фикерләп караган кавемгә монда аятьләр бар!»* («Рум» сүрәсе, 21 нче аять).

Ислам диндар вә күркәм холыклы хатынга никахланырга өнди. Матурлык, дәрәҗә һәм байлыкка гына кызыгуны чикли. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтүенчә: *«Кем бай хатынга өйләнсә, фәкать фәкыйрьлекне әзерли. Нәсәбе өчен өйләнсә, фәкать түбәнгә төшәчәк. Инде кем күзен хәрәмнән саклау вә үзен тыю өчен өйләнсә, Аллаһы аңа хатынны, хатынга исә аны мөбарәк кыла».*

Моннан кыяфәткә игътибар итәргә ярамый дигән мәгънә килеп чыкмый. Әмма холыксызлык һәрбер яхшылыкны юкка чыгара, һәркайсы күренешне шөбһә өстенә куя. Бу хәлдә нык гаиләви элемтәне хасил иттерү өчен мал да, матурлык та файда бирми.

Пар сайлаган вакытта аның тиң булуына игътибар ителү яхшы. Бу шарт аеруча безнең хәнәфи мәзһәбендә игътибарга алына һәм өч юнәлештә карала: 1. Игътикадтагы тиңлек. 2. Икътисадый тиңлек. 3. Кәсеп-һөнәрдәге тиңлек. Гади бер мисал: бик бай булган кешенең кызы үтә дә фәкыйрь адәмгә тормышка чыкса, мондый никах күп вакытта хәерле тәгәлләнми. Әмма бу тиңлек никах дөреслегенә шарт булып тормый, ул фәкать игътибарга алынырга тиешле бер мәсьәлә генәдер.

Булачак килен белән кияүнең танышу мәсьәләсенә килгәндә исә, түбәндәге хәдисне искә төшерик. Мөгыйрә ибн Шугъба радыйаллаһу ганһе бер хатынга яучы җибәргәндә, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Аны күр, чөнки гаилә дәвамлы булу өчен бу кирәк»,* – диде. Танышу-күрешү тыелмаган, һәм бу эштә яшьләр зинага этәрелми, чөнки танышу дус яки туганнар хозурында үтәргә тиеш. Күрү мәсьәләсендә күпчелек факиһлар йөз вә ике кулга карашны мөбаһ дигәннәр.

Имам Әбү Хәнифә радыйаллаһу ганһе аякның ашык сөягенә хәтле күрүгә рөхсәт биргән.

«Ән-Ниса» сүрәсендә әйтелгән: *«Аллаһы кешеләрнең берсен икенчесеннән өстенрәк иткәнгә күрә һәм ирләр үз малларын сарыф кылганга күрә, алар хатыннарга караганда өстенрәк»* (34 нче аять). Гаилә

№ 22 (1149), 26 май 2012 ел